*октябрь, 2018 ел*

# Гимназия сулышы №5

***25 нче гимназия укучылары газетасы***

Кадерле укучылар, хөрмәтле укытучылар ! Яңа уку елы белән котлыйбыз!

1 сентябрьнең кояшлы иртәсендә 153 беренче сыйныф укучысы өчен тәүге кыңгырау чыңлады. Тантаналы линейкадан соң 1 а,б,в,г,д сыйныф укучылары өчен Тынычлык дәресе үткәрелде.



**Котлыйбыз!**



Казакова Әлфия Фатыйх кызы- I квалификацияле рус теле һәм әдәбияты укытучысы, 2006 нчы елдан Россия мәгарифенең Мактаулы хезмәткәре дигән исемне йөртә. 2018 нче елда ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының әдәбият фәне буенча Бөтенроссия олимпиадасының республика этабында җиңүче Хрущёва Дарьяны әзерләгән өчен Мактау грамотасы һәм 2018 нче елда РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының мәктәп укучыларының әдәбият фәне буенча Бөтенроссия олимпиадасының йомгаклау этабында призёр Хрущёва Дарьяны әзерләгәне өчен Мактау грамотасы белән бүләкләнде. Котлыйбыз!

**Рәхмәт, Сезгә, укытучыбыз !**

Безнең гимназиядә 82 укытучы укыта. Шуларның берсе- Казакова Әлфия Фатыйх кызы - безнең сыйныф җитәкчесе, рус теле һәм әдәбияты укытучысы. Ул һәр дәрестә үзара аңлашу, дустанә мөнәсәбәт халәте булдыра. Хәзерге рухи кыйммәтләр югала барган заманда игелекле, кешелекле, башкаларның кичерешләрен аңлый белергә өйрәтә безне Әлфия Фатыйх кызы. Л.Н.Толстой, А.С.Пушкин , А.П.Чехов кебек классик язучыларның әсәрләре аша, безне- укучыларын, киләчәк тормышта үз урынын таба алырлык шәхес буларак күрергә тели ул. Әлфия Фатыйх кызы безне гадилеге белән дә үзенә тарта. Эшкә килгәндә ул һәр укучысының исемен әйтеп, ягымлы итеп

исәнләшә. Әлфия Фатыйх кызы игътибарлы бакчачы кебек укучыларын һәрьяклап үстерә. Шуңа да бакча җимешләре яхшы уңыш бирә. Аның укучылары рус теленнән бердәм дәүләт имтиханын уңышлы бирә, фән олимпиадасында җиңүчеләр була. Яраткан укытучыбыз узган җәйдә юбилеен билгеләп үтте. Без аңа сәламәтлек, шатлык-бәхет, авыр һәм мактаулы эшендә яңа җиңүләргә ирешүен телибез. Якупова Гүзәл, Паненко Арина ***P.S.***Әлфия Фатыйховна, гомер бәйрәмегез белән, Сезне! Укучыларыгыз һәрвакыт уңышлары белән сөендерсеннәр!

## Алар ярдәмгә мохтаҗ

Балаларда дүрт аяклы дусларыбызга карата кешелеклелек, ярдәмчеллек сыйфатларын тәрбияләү максатыннан, гимназиядә игелеклелек акциясе оештырыла. Рус теле һәм әдәбияты укытучысы Варганова Юлия Валентин кызы бу чарада укучыларның актив катнашуларын билгеләп үтте. Урамда калган эт-мәчеләргә карата укучыларның , аларның әти-әниләренең битараф булмавы сөенечле хәл, әлбәттә. Алабуга шәһәрендә урнашкан «Тугрылык» приюты хезмәткәрләре гимназия укучыларына зур рәхмәтләрен җиткерделәр. Җыелган азык, һичшиксез, приютта яшәүче эт-мәчеләргә ярдәм булачак», -диде Юлия Валентин кызы. Садреева Эльмира






**Өлкәннәр көне уңаеннан**

1 октябрь көнне гимназиядә Халыкара өлкәннәр көненә багышланган чара үткәрелде. Микрорайонда яшәүче әби-бабайларны гимназия укучылары җылы каршы алдылар. Актлар залында өлкәннәр өчен котлаулар яңгырады.Укучылар башкарган дәртле биюләрне , матур җырларны әби-бабайлар бик ошаттылар. Бәйрәм ашханәдә чәй өстәле артында дәвам итте. Өлкән кешеләргә ихтирамны бәйрәм көнендә генә түгел, һәрвакыт күрсәтергә кирәк. Шуны онытмаска иде. Мөхәммәдиева Әлфия

**Укытучыларны бәйрәм белән котлыйбыз !**

Бу көнне 11 сыйныф укучылары гимназия администрациясе дигән мактаулы исемне алдылар. Унберенчеләр укытучылар ролен башкарды, ә укытучылар хореография нигезләренә, оригами ясау серләренә төшенделәр. Бәйрәм булгач концерт та була, билгеле. Укучыларның кызыклы чыгышларын карап, укытучылар рухәтләнеп ял иттеләр. Үзидарә көне күңелле узды ! Бакирова Алия

**Укытучылар, чын күңелдән рәхмәт, Сезгә!**
**Биргән өчен йөрәк җылыгызны.**

**Ярты сүздән, ярты караштан Сез**
**Аңлыйсыздыр кебек уебызны.**



## Татарча диктант

20 ил һәм Россиянең 60 төбәге катнашкан «Татарча диктант» акциясенә гимназия укучылары, укытучылар, әти-әниләр дә кушылды.

Чараның максаты – татар телендә хатасыз язарга өйрәтү, әдәби татар телен кулланучылар даирәсен арттыру иде. 9 б сыйныфыннан Трофимова Эльвира, Латыйпова Динара, 10 сыйныфтан Герасимов Данил, Миндарова Алсу, Садыйкова Әдилә, Хәйруллина Диләрә, Якупова Гүзәл татар теленнән белем дәрәҗәләрен сынап карадылар.

Акциянең йомгаклау өлешендә һәр катнашучыга сертификат биреләчәк.

Хәйруллина Диләрә





## Гимназия кунаклары

Болонка, чихуахуа, немец шпицы, бульдог… Менә шундый төрле токымлы этләр кунак булды октябрьның бер шимбәсендә безнең гимназиядә . 1-11 сыйныф укучылары һәм укытучылар үзләренең дүрт аяклы дуслары белән «Дог-шоу» да катнаштылар. Барлыгы 34 эт үз хуҗасы белән тәкъдим итү, дефиле конкурсында үзара ярыштылар. Иң яхшыларга дипломнар һәм махсус бүләкләр тапшырылды. Ваһапова Рената



Кадерле дуслар! Яңа уку елының беренче чиреге сизелмичә үтте дә китте. Алда көзге каникуллар ! Кызыклы, матур булсын ялыгыз. Яңалыклар турында безгә түбәндәге электрон адреска языгыз: 3023001035 @edu.tatar.ru

Редактор: Якупова Гүзәл Проект җитәкчесе: Шарапова Н.Н.